**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26нчы август, 2022 ел** **№ 196**

**Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 16 маендагы 163 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәткә керүгә тигез мөмкинлек өлешендә муниципаль хезмәтнең төп принципларын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы Кодексына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 13 апрелендәге 138 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (13.10.2017 №168, 28.03.2018 №202, 11.07.2018 №226, 31.08.2018 №238, 17.04.2019 №287, 22.05.2020 №371 карарлары редакциясендә), кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләргә таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 16 маендагы 163 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә, 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

г) муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм кече төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләгәндә;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» мәгълүмат сайтында https://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе А.П. Афанасьевка йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров